**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы**
**Сармаш-Баш авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**№27** **20.04.2021**

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Сармаш-Баш авыл җирлеге муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәне раслау хакында» 2020 елның 28 декабрендәге 20 номерлы Зәй муниципаль районының Сармаш-Баш авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Зәй муниципаль районының Сармаш-Баш авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Сармаш-Баш авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Сармаш-Баш авыл җирлеге муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәне раслау хакында» 2020 елның 28 декабрендәге 20 номерлы Зәй муниципаль районының Сармаш-Баш авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4.16 пунктта:

а) икенче абзацта «күрсәтелгән мөлкәтне» сүзләрен «күрсәтелгән карарны» сүзләре белән алмаштырырга;

б) 17 абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

в) 19 абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

1.2. 4.20 пунктта «4.5.6. пункт белән» сүзләрен «әлеге нигезләмәнең 4.19 пункты белән» сүзләре белән алмаштырырга;

1.3. 8.3 пунктның 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«-электр, элемтә һәм үткәргеч торба линияләрен, кайнар су белән тәэмин итүнең үзәкләштерелгән системаларын, салкын су белән тәэмин итү һәм (яисә) юынтык суларны чыгару линияләрен, системалар һәм мелиорация линияләрен салу һәм алардан файдалану мөмкинлеген тәэмин итәргә.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU), җирлек торак пунктлары территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында һәм Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

3. Карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Совет рәисе Р.М.Фәсхетдинов